**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**
**24.09.2018**

**БОЕРЫК**
**500**

Казан шәһәре №

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендә кул куелган 906 нчы номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» карары нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет төзергә.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турындагы теркәлә торган нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип санарга:

2015 елның 17 ноябрендә кул куелган 723 нче номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында»;

2016 елның 14 мартында кул куелган 162 нче номерлы «2015 елның 17 ноябрендә кул куелган 723 нче номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында»гы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү турында»;

2016 елның 18 ноябрендә кул куелган 728 нче номерлы «2015 елның 17 ноябрендә кул куелган 723 нче номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында»гы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү турында».

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.М.Миңгуловка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
**24.09.2018 № 500**
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм тормышка ашыруда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмаларның хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләрне карый, шулай ук әлеге нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне тормышка ашыра торган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) каршындагы киңәш органы булып тора.

1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Министрлык боерыгы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендә кул куелган 906 нчы номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет төзү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә раслана.

1.3. Үз эшчәнлегендә Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм карарлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм боерыкларына, шулай ук әлеге нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим характерында.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында тормышка ашыра.

1.6. Иҗтимагый советның эшчәнлеге ирекле нигездә, ачыклык һәм

партнерлык принципларында һәм катгый рәвештә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына яраклаштырып төзелә.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен гражданлык җәмгыяте вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынулары нигезендә тормышка ашыра.

## 2. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

2.1. Иҗтимагый советның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- гражданнарның хаҗәтләрен һәм кызыксынуларын исәпкә алу, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштыруда һәм тормышка ашыруда гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмаларның хокукларын яклау;

- иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади берләшмәләр вәкилләрен Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә җәлеп итү, министрлык эшчәнлегенең хәбәрдарлык һәм ачыклык принципларын тормышка ашыру;

- Министрлык карамагындагы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәт күрсәтүләренең сыйфатына иҗимагый тикшерүне көчәйтү, Татарстан Республикасында физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә ачыклык, законлылык һәм профессиональлек принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

физик тәрбия һәм спорт мәсьәләләренә кагыла торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза, шулай ук Министрлык тарафыннан эшләнә торган дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышу үткәрү;

Министрлык карарлар кабул иткән вакытта җәмәгать фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча иҗтимагый мәгълүматлылыкны арттыру.

2.3. Иҗтимагый советның максатлары һәм бурычлары аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси ситуацияне истә тотып, үзгәрергә һәм аларга өстәмәләр кертелергә мөмкин.

## 3. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ СОСТАВЫ

3.1. Иҗтимагый советның составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе буенча формалаштырыла.

3.2. Иҗтимагый совет Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә ирекле нигездә 8 кешелек составта формалаштырыла.

3.3. Иҗтимагый совет составына Россия Федерациясе гражданнары, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм башка социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре керә ала. Шул ук вакытта аларның Иҗтимагый совет алдына куелган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен зарури булган һөнәри сыйфатлары, тиешле белем дәрәҗәсен, әлеге өлкәдә эш тәҗрибәсен дә кертеп, исәпкә алына.

Иҗтимагый совет составына әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән затлар белән беррәттән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының яртысыннан ким булмаган санда Татарстан Республикасы Иҗтимагый советы тәкъдим иткән затлар да кертелә.

Иҗтимагый совет составына элек Россия Федерациясе дәүләт вазифаларында, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм башка Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм башка Россия Федерациясе субъектлары дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, муниципаль вазифалар һәм муниципаль хезмәт вазифаларында эшләгән затлар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән артык булмаган санда керергә мөмкин.

3.4. Хәзерге вакытта Россия Федерациясе дәүләт вазифаларында, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм башка Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазифаларында, Татарстан Республикасы һәм башка Россия Федерациясе субъектлары дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларында, муниципаль вазифалар һәм муниципаль хезмәт вазифаларында эшли торган затлар, суд карары нигезендә хокукка сәләтсез дип табылган затлар, хөкем ителүе юкка чыгарылмаган һәм кире алынмаган затлар, шулай ук 2005 елның 4 апреленнән 32 нче номерлы «Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы турында» Федераль законы буенча Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзалары була алмый торган башка затлар Иҗтимагый совет әгъзалары була алмыйлар.

3.5. Иҗтимагый советның аерым (персональ) составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.6. Министрлык Иҗтимагый совет составы расланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча Иҗтимагый советның беренче утырышын оештыра, анда әгъзалар арасыннан Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасары сайлана. Карар ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.7. Иҗтимагый совет рәисен һәм аның урынбасарын вазифаларыннан азат итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба - министр) мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисе һәм аның урынбасарының шәхси гаризасы буенча яки Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санының биштән береннән дә ким булмаган санда Иҗтимагый совет әгъзалары группасы тәкъдиме буенча Иҗтимагый советта карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.8. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибен билгели.

3.9. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы, Иҗтимагый советның яңадан формалаштырылган составының беренче утырышын үткәргән көннән башлап, өч ел тәшкил итә.

3.10. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча Министрлык боерыгы нигезендә түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аңа карата җинаять кылуда гаепләү;

аңа административ арест рәвешендә административ җәза билгеләү;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (тәкъдим итү) органына кандидат, җирле үзидарә органында сайлап куела торган вазифага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле буларак теркәү, шулай ук Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициативалы группа составына керүе очрагында.

3.11. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре вакыты чыгу;

аның тарафыннан Иҗтимагый советтан чыгу турында гариза бирү;

сәламәтлеге торышы буенча аның Иҗтимагый совет эшендә катнашу мөмкинлеге булмау;

аңа карата чыгарылган суд гаепләү карарының законлы көченә керүе;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез яки хәбәрсез булмаучы дип табылу;

аның этика нормаларын тупас бозуы – утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары санының күпчелек тавышы белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә кичектергесез сәбәпләр булмыйча системалы рәвештә (өч тапкырдан артык) катнашмау;

кичектергесез сәбәпләр булмыйча системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасарының тапшырылган эшләрен башкармау;

аның Россия Федерациясе дәүләт вазифасына, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, муниципаль вазифага һәм муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнүе;

аның чит ил дәүләте гражданлыгын (гражданлыгында булу) алуы;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу.

3.12. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре туктатылу Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе яки рәис урынбасары күрсәтмәсе буенча, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.11 пунктында каралган хәлләр ачыкланган очракларда Министрлык боерыгы буенча тормышка ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.11 пунктының дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган хәлләр килеп чыгу турында  Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

## 4. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТ ӘГЪЗАЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәге хокукларга ия:

Министрлык инициативасы белән уздырыла торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һ.б.ларда) катнашу, федераль законнар буенча аларга керү чикләнә торган дәүләт сере булган белешмәләрне, шәхси белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматларны һәм чикләнгән рөхсәте булган мәгълүматны куллану белән бәйле булган чаралардан тыш;

инициатива тәртибендә Иҗтимагый советка аналитик язмалар, чыгышлар һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый совет эш планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә тәкъдимнәр кертү;

Иҗтимагый совет утырышына көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау өчен катнашуга чакырыла торган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертү;

Иҗтимагый совет әгъзалары составыннан чыгу.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасы бурычлы:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән эшләрне үтәргә;

Әлеге Нигезләмәдә каралган Иҗтимагый совет эше тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

аңа тапшырылган бурычларны үтәү өчен Иҗтимагый совет оештыра торган эксперт, эшче группалар, комиссияләр, башка эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. ИҖТИМАГЫЙ СОВЕТНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

4.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе тәкъдим итүе буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар буенча оештыра.

4.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыру Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм Министрлык тәкъдимнәре буенча тормышка ашырыла.

4.3. Иҗтимагый совет утырышлары кварталга бер тапкырдан да азрак уздырылмый. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Министрлык инициативасы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 мартында кул куелган 214 нче номерлы «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшли торган башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерү уздырмый торып кабул ителми торган норматив хокукый актлар һәм башка документларның составын раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшли торган башкарма хакимиятнең әлеге органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерү уздырмый торып кабул ителми торган норматив хокукый актлар һәм башка документларның исемлегендә каралган норматив хокукый актларның Министрлык эшләгән проектларына һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәүгә билгеләнгән тәртиптә юллана торган Министрлыкның норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында уздырыла.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының өчтән ике өлешеннән ким булмаган әгъзасы катнашкан вакытта

тулы хокуклы дип санала. Иҗтимагый совет әгъзасы, утырышта шәхсән катнашу мөмкинлеге булмаганда, алдан моның турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәис урынбасарына, яисә Иҗтимагый совет җаваплы сәркатибенә хәбәр итеп, көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз тавышын һәм үз фикерен язмача, факсимиль яисә электрон почта аша башка Иҗтимагый совет әгъзасына юлларга хокуклы. Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның башка әгъзаларына тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлары проектларын (норматив хокукый актлар) карау Министрлык тарафыннан аларны Иҗтимагый советка юлланган көннән ун календарь көне эчендә тормышка ашырыла. Шул ук вакытта алар буенча Иҗтимагый советның бәяләмәләрен бирү максатларында тавыш бирү уздыру Иҗтимагый совет әгъзаларының барысының да фикерен сорау рәвешендә читтән торып тавыш бирү юлы белән дә тормышка ашырылырга мөмкин, сорау нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул – Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана. Мондый тавыш бирү тапшырыла һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең дөреслеген тәэмин итә торган почта, телеграф, телетайп, телефон, электрон яки башка элемтә чаралары аша документлар алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин. Читтән торып тавыш бирү очрагында Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына, аның барлык әгъзаларына тәкъдим ителә торган көн тәртибе, Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү тиеш булган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) аны уздыру көненә җиде көннән дә кимрәк булмаган вакытта юллана. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк булган очракта Минстрлыктан өстәмә материаллар һәм карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча мәгълүмат сорыйлар һәм алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Иҗтимагый совет утырышында рәислек иткән затның тавышы хәлиткеч булып тора.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе, ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары үткәрә.

5.6. Аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләргә туры китереп кабул ителә торган Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында була һәм кызыксынган затларга Иҗтимагый совет утырышы карарыннан күчермә рәвешендә яисә Иҗтимагый совет карары буенча башка ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә сайтында урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелекне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышларын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эше планын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны раслау өчен Иҗтимагый советка тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышларын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет тәкъдимнәрен, беркетмәләрен һәм Иҗтимагый советның башка документларын имзалый;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнелгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына эшләр бирә;

Иҗтимагый совет исеменнән сорауларны, рекомендация һәм тәкъдимнәрне, җаваплар, аңлатмалар һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган башка функцияләрне тормышка ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

ул рәсми рәвештә булмаган вакытта Иҗтимагый совет рәисе функцияләрен башкара;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышларының көн тәртибен төзи һәм аны раслауга Иҗтимагый совет рәисенә тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган башка функцияләрне башкара.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирә, аларны кирәк булган мәгълүмати-белешмә материаллар белән тәэмин итә;

Иҗтимагый совет һәм Министрлыкның оештыру үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм аларның үтәлешен тикшерүне тормышка ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында

мәсьәләләрне тыңлау һәм тикшерүгә мәсьәләләр хәзерләү өчен эшче, эксперт органнарга һәм башка эшче органнарга берләшә, материаллар әзерләүгә, Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килешеп, Иҗтимагый совет составына керми торган белгечләрне җәлеп итә ала.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышына Иҗтимагый советта карала торган мәсьәләләр буенча кирәк булган белешмәләр һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнар, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булып тормаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнашырга мөмкин.

5.12.1. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый советы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына аларны карау планлаштырыла торган Иҗтимагый совет утырышының билгеләнгән датасына кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш. Материалларны бераз соңрак вакытларда бирү Иҗтимагый совет рәисе яисә рәис урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Министрлык тормышка ашыра.